БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» 12 2023 ел № 323

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында» Балтач районы башкарма комитетының 2022 елның 15 октябрендәге 293 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексын, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач районы башкарма комитетының 2022 елның 15 октябрендәге 293 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач районы башкарма комитетының
2023 елның «11» 12
323 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның
кыска сроклы планы.

I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның әлеге кыска сроклы планы (алга таба - кыска вакытлы план, муниципаль программа ярашлы итеп) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә муниципаль программаны гамәлгә ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын конкретлаштыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның планлаштырыла торган хезмәт һәм (яки) эш төренә төзәтмәләр кертү, дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен билгеләү, капиталь ремонт ясауга муниципаль ярдәм күләмен билгеләү максатларында эшләнгән.

II. Кыска вакытлы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска вакытлы планның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Балтач муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

гражданнар өчен имин һәм уңайлы яшәү шартлары булдыру;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

кыска вакытлы планның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

кыска вакытлы планны башкаручыларны сайлап алуның ачык һәм гавами процедураларын эшләү һәм үтәү;

чыдам материаллар һәм ресурслар саклый торган технологияләр кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник чишелешләрне һәм комплекслылыкны куллану.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру срогы - 2023, 2024, 2025 еллар.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 2,680 мең кв.метр булган 3 күпфатирлы йортта яшәүче 158 граждан өчен имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге кыска вакытлы планны үтәү буенча планлаштырылган күрсәткечләр кыска вакытлы планга 1номерлы кушымтада күрсәтелгән.

## III. Кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге

Балтач муниципаль районының кыска вакытлы планны үтәүдә катнашучы шәһәр һәм авыл җирлекләре исемлеге, мондый җирлекләр территориясендә түбәндәгеләр булуын исәпкә алып формалаштырылган:

а) Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгән;

б) Балтач муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның кыска вакытлы (еллык) муниципаль планнары дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән расланды һәм килештерелде.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыруда Балтач шәһәр җирлеге катнаша.

## IV. 2023 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме.

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 145 |
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 80 |
| Су чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 80 |
| Фасадны ремонтлау | кв. метр | 1100 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 96 |

2024 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме.

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 0 |
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 80 |

| | | |
|---|---|---|
| Су чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 80 |
| Фасадны ремонтлау | кв. метр | 750 |
| Подъездларны ремонтлау | кв. метр | 0 |

2025 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме.

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 145 |
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 80 |
| Су чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | пог.м. | 80 |
| Фасадны ремонтлау | кв. метр | 1100 |

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры» кыскача сроклы планга 2 номерлы кушымтада китерелде.

V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар һәм күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең акчалары тора.

Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме түбәндәгеләрне тәшкил итәчәк:

- **2023 ел:** 2748880,00 сум, шул исәптән :
  Татарстан Республикасы бюджеты - 778 784,79 сум;
  җирле бюджетлар - 1 128 000,00 сум;
  күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре - 628 799,62 сум;
- **2024 ел:** 6179387,03 сум, шул исәптән :
  Татарстан Республикасы бюджеты - 798 911,10 сум;
  җирле бюджетлар акчасы - 1128000,00 сум;
  күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең акчасы - 4252475,93 сум;
- **2025 ел:** 4165455,82 сум, шул исәптән :
  Татарстан Республикасы бюджеты - 778 784,79 сум;

җирле бюджетлар акчасы– 1128000,00 сум;
күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре - 2 238 544,72 сум.

**2023** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтлау уткәрү буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сумнарда |
|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 372829,03 |
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремонтлау яки алмаштыру | 154660,62 |
| Су чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 345226,60 |
| Фасадны ремонтлау | 703708,07 |
| Подъездларны ремонтлау | 860027,05 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 72702,04 |
| Техник күзәтчелек (Төзелеш контролен гамәлгә ашыру) | 26431,00 |
| Барлыгы: | **2 535 584,41** |

**2024** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтлау уткәрү буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сумнарда |
|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 0 |
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү инженерлык системаларын ремотлау яисә алмаштыру | 180000,00 |
| Су чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 360000,00 |
| Фасадны ремонтлау | 5416000,03 |
| Подъездларны ремонтлау | 0 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 185148,00 |
| Техник күзәтчелек (Төзелеш контролен гамәлгә ашыру) | 38239,00 |
| Барлыгы | **6 179 387,03** |

**2025** елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә
финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтлау уткәрү буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сумнарда |
|---|---|
| Электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 328520,00 |
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итүнең инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 214880,00 |
| Су чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яисә алмаштыру | 328000,00 |
| Фасадны ремонтлау | 3078519,82 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 161652,00 |
| Техник күзәтчелек (Төзелеш контролен гамәлгә ашыру) | 53884,00 |
| Барлыгы | **4 165 455,82** |

Капиталь төзекләндерү үткәрүнең бәясен күрсәтеп, күпфатирлы йортлар исемлеге кыска вакытлы планга 3 нче кушымтада китерелгән.

VI. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру механизмы

Әлеге кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру Балтач район башкарма комитеты, ТСЖ, идарәче оешмалар, биналар милекчеләре, подрядчы оешмалар (алга таба - кыска вакытлы планны башкаручылар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Балтач район башкарма комитеты түбәндәгеләрне башкара:

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) Региональ программаны гамәлгә ашыру буенча кыска вакытлы (еллык) муниципаль планнарны формалаштыра һәм җибәрә;

Министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документлар тапшыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнаша;

җирле бюджет акчаларын Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге кыска вакытлы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга күчерә;

Региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча эшләрнең техник заказчысы функцияләрен гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләрнең актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын, күпфатирлы йортны капиталь ремонт өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчадан файдалану очракларыннан тыш, шулай ук чыгымнар арткан очракта, килештерә;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау эшләрен уздыруга бүлеп бирелә торган акчалардан максатчан файдалану мониторингын гамәлгә ашыралар;

Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек буенча кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру максатларында белешмәләр базасын төзиләр һәм аны актуаль хәлдә хуплыйлар (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча белешмәләр);

Министрлыкка һәм кыска вакытлы планның башка башкаручыларына Фондка хисап формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыра.

Торак милекчеләре ширкәте (ТСЖ), идарәче оешмалар түбәндәгеләрне үти:

капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләргә ай саен түләүләр исәпләнә, капиталь ремонтка кертемнәр рәвешендә түләнә торган урыннар милекчеләреннән акча җыюны гамәлгә ашыра, региональ оператор счетында капиталь ремонт фонды булдырылган очракта, региональ оператор счетында милекчеләрнең кертемнәрен капиталь ремонтка кертемнәре региональ оператор счетына күчерә, һәр милекче буенча түләүләр турында мәгълүматны торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм мониторинглауның дәүләт программасы үтәлешен формалаштыру һәм мониторинглауның Интеграцияләнгән мәгълүмат-аналитик системасына кертә: https://bars-monjf.tatarj-u/monjf/;

капиталь ремонтка түләүләр буенча урын милекчеләренең бурычлары барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар күрәләр;

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә карата җитешсезлек (дефект) ведомостьларын, башкарылган эшләрнең актларын килештерәләр;

региональ оператор белән түләү документларын формалаштыру өчен һәм капиталь ремонт өчен түләүләр буенча милекчеләрнең ай саен исәпләүләрен һәм түләүләрен региональ оператор счетына күчерүне тәэмин итү өчен шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу белән проект документларын әзерләүне тәэмин итәләр;

урын милекчеләренә капиталь ремонт башлану вакыты, хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең кирәкле исемлеге һәм күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт ясауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр кертәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышларын оештыралар:

капиталь ремонт объектларына керүне рөхсәт итүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларын һәм аларны файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән, капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга алуда катнашалар;

күпфатирлы йортка капиталь ремонт буенча җитешсезлек (дефект) ведомостьларын, проект-смета һәм башкарма документларны күпфатирлы йортны һәм аңа керә торган инженерлык системаларын авариясез эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия вакытыннан да ким булмаган вакыт дәвамында саклыйлар.

Урын милекчеләре түбәндәгеләрне башкаралар:

капиталь ремонт эшләре күләменә карата житешсезлек (дефект) ведомостьларын, тикшерү актларын килештерәләр;

күпфатирлы йортларга капиталь ремонтны вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тотуда, шулай ук, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларын һәм аларны файдалануга тапшыру актларын имзалау хокукы белән, капиталь ремонттан соң күпфатирлы йортларны файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча кыска вакытлы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән вакыт эчендә эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;-

КС-2, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләрнең актларын формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешма:

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыра;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнаша, башкарылган эшләрнең актларын килештерә;

объектны файдалануга кабул итүдә катнаша, объектны файдалануга кабул итүнең актын килештерә;

күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

проект оешмасыннан проект-смета документларын кабул итә;

күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь төзекләндерү буенча күрсәтелгән хезмәтләрне (яки) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул кую датасыннан соң 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь төзекләндерү үткәрү турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән, проектның, смета документларының, хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) капиталь төзекләндерү эшләрен башкару турында килешүләрнең күчермәләре) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документлар, финанс документларыннан тыш, тапшыра;

техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен гамәлгә ашыра.

Район массакүләм мәгълүмат чаралары - «Хезмәт»(«Азьлане») газетасы һәм «Кайтаваз» теле-радио компаниясе массакүләм мәгълүмат чараларында кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру барышын даими яктыртып тора.

Кыска вакытлы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

VIII. Күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт эшләрен

башкару өчен подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 1 июлендәге 615 номерлы "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен подрядчы оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган коммерциягә карамаган оешма функцияләрен үтәү максатларында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тәртибе турында" карары нигезендә региональ оператор тарафыннан сайлап алына.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына
1 нче кушымта

**Планлаштырылган күрсәткечләр**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын үтәү буенча**

| № т/б | Муниципаль берәмлек атамасы | Күпфатирлы йортларның гомуми мәйданы, кв. метр | Региональ программа расланган көнгә күпфатирлы йортларда теркәлгән яшәүчеләр саны | Күпфатирлы йортлар саны | | | | | Капиталь ремонт бәясе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | барлыгы | I квартал | II квартал | III квартал | IV квартал | барлыгы |
| **2023 ел** | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач муниципаль районы | 909,03 | 53 | | | | 1 | 1 | | | | 2 535 584,41 | 2 535 584,41 |
| **2024 ел** | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Балтач муниципаль районы | 894,46 | 56 | | | | 1 | 1 | | | | 6 179 387,03 | 6 179 387,03 |
| **2025 ел** | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | Балтач муниципаль районы | 876,40 | 49 | | | | 1 | 1 | | | | 4 165 455,82 | 4 165 455,82 |

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль
территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда
іуми мөлкәткә капитал ремонт буенча муниципаль
ммaны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның
кыска сроклы планына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры**

| № т/б | Күпфатирлы йорт адресы | Капиталь ремонт бәясе, БАРЛЫГЫ | Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән төрләр | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ташландык суларны чыгаруның йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | | фасадны ремонтлау | | электр белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау | | салкын су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге системаларын ремонтлау | | подъездларны ремонтлау | | Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | төзелеш контролен гамәлгә ашыру |
| | | сумнарда | пог. метр | сумнарда | кв. метр | сумнарда | фатир метр | сумнарда | пог.м | сумнарда | фатир метр | сумнарда | сумнарда | сумнарда |
| 1 | 2 | 3 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | | |
| **2023 ел** | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач штп,Ленин ур., 158 й. | 2 535 584,41 | 124 | 345226,60 | 1100 | 703708,07 | 96 | 372829,03 | 104 | 154660,62 | 96 | 860027,05 | 72702,04 | 26431,00 |
| | Барлыгы: | 2 535 584,41 | 124 | 345226,60 | 1100 | 703708,07 | 96 | 372829,03 | 104 | 154660,62 | 96 | 860027,05 | 72702,04 | 26431,00 |
| **2024 ел** | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач штп,Ленин ур., 133А | 6 179 387,03 | 80,00 | 360 000,00 | 750 | 5 416 000,03 | 0 | 0 | 80 | 180 000,00 | 0 | 0 | 185 148,00 | 38 239,00 |
| | Барлыгы: | 6 179 387,03 | 80,00 | 360 000,00 | 750 | 5 416 000,03 | 0 | 0 | 80 | 180 000,00 | 0 | 0 | 185 148,00 | 38 239,00 |
| **2025 ел** | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач штп, Ленин ур., 135 й. | 4 165 455,82 | 80,00 | 328 000,00 | 1 100,00 | 3 078 519,82 | 145,00 | 328 520,00 | 80,00 | 214 880,00 | 0,00 | 0,00 | 161 652,00 | 53 884,00 |
| | Барлыгы: | 4 165 455,82 | 80,00 | 328 000,00 | 1 100,00 | 3 078 519,82 | 145,00 | 328 520,00 | 80,00 | 214 880,00 | 0,00 | 0,00 | 161 652,00 | 53 884,00 |

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына
3 номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча муниципаль программаны 2023, 2024, 2025 елларда гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән күпфатирлы йортлар исемлеге**

| № т/б | Күпфатирлы йорт адресы | Ел | | Стенаның материалы | Катлар(этаж)саны | Подъездлар саны | күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, барлыгы | Күпфатирлы йорт урыннарының мәйданы | | Региональ программа расланган көнгә күпфатирлы йортта теркәлгән кешеләр саны | Ремонт төре | Капиталь ремонт бәясе | күпфатирлы йортның гомуми мәйданының 1 кв.метрында капиталь ремонтның чагыштырма бәясе (удельная стоимость) | Күпфатирлы йортның гомуми мәйданының 1 кв. метрында капиталь ремонтның чик бәясе | Эшләрне тәмамлауның планлаштырылган датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | файдалануга тапшыру | соңгы капиталь ремонтны тәмамлау | | | | | барлыгы | шул исәптән гражданнар милкендәге торак урыннарда | | | | | | |
| | | | | | | | кв. метр | кв. метр | кв. метр | кеше | | сумнарда | сум/кв. метр | сум/кв. метр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 18 | 19 | 20 |
| Балтач муниципаль районы | | | | | | | | | | | | | | | |
| | 2023 ел | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач штп,Ленин ур., 158 й. | 2000 | 2014 | Кирпеч | 4 | 2 | 909.03 | 909,03 | 909,03 | 53 | Өлешчә | 2 535 584,41 | 2789,3 | 14 000,00 | 31.12.2023 |
| 2023 елга район буенча барлыгы | | | | | 4 | 2 | 909,03 | 909,03 | 909,03 | 53 | | 2 535 584,41 | | | |
| | 2024 ел | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач штп,Ленин ур., 133А | 1998 | 2014 | Кирпеч | 4 | 2 | 894,46 | 894,46 | 894,46 | 56 | Өлешчә | 6 179 387,03 | 7148,3 | 14 000,00 | 31.12.2024 |
| 2024 елга район буенча барлыгы | | | | | 4 | 2 | 894,46 | 894,46 | 894,46 | 56 | | 6 179 387,03 | | | |
| | 2025 ел | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Балтач штп,Ленин ур., 135 й. | 2008 | 2008 | Кирпеч | 4 | 2 | 876,40 | 876,40 | 876,40 | 49 | Өлешчә | 4 165 455,82 | 4752,9 | 14 000,00 | 31.12.2025 |
| 2025 елга район буенча барлыгы | | | | | | | 876,40 | 876,40 | 876,40 | 49 | | 4 165 455,82 | | | |